РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

***Красновидовского сельского Поселения Камско-Устьинского муниципального района***

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**Красновидово авыл**

**БАШЛЫГЫ**

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

# КАРАР

**2019 елның 4 декабре** **14 номерлы**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР бирәм:

1. Красновидово торак пунктында яшәүчеләр катнашында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча ***халык җыенының беренче этабын*** 2019 елның 16 декабрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә:
Красновидово авылы, Яңа ур., Набережная ур., Мәктәп ур. Красновидово авыл җирлеге,
2. Красновидово авылы торак пунктында яшәүчеләр катнашында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча ***халык җыенының икенче этабын*** 2019 елның 16 декабрендә 13 сәгать 30 минутка билгеләргә:
Красновидово авылы, Тынычлык ур., Горький ур., Совет ур.

3. Красновидово торак пунктында яшәүчеләр катнашында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча ***халык җыенының өченче этабын*** 2019 елның 16 декабрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә:

Красновидово авылы, Элеватор урамы, Нагорная урамы, Заовражная -1 нче урамы, Заовражная-2 нче урамы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 500 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл өчен җибәрү белән килешәсезме?:

- поселок эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- суүткәргечне һәм су чыганакларын ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

ТР Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4 нче йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 3 көн эчендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы В. П. Оленин